ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ЯДЫГЕРЬСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башлыгы КАРАРЫ

14 июль 2023 ел №5

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең Ядегәр авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 18 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Ришвәтчелеккә каршы тору турында» Федераль закон нигезендә, «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге УП-711 номерлы Указы нигезләмәләрен исәпкә алып карар бирәм:

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең Ядегәр авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 18 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 нче пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеге һәм тулылыгы (ришвәтчел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлешендә)»

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге пунктта каралган тикшерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булган мәгълүматны кабул итүгә кадәр өч ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу таләпләрен, «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасының башка федераль законнары, норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бурычларын үтәүләре (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр)».

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

в) 6 пунктта:

беренче абзацта «1 пунктның «б» һәм «в» пунктчалары белән» сүзләрен «1 пункт» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге «а.1» пунктчасы белән тулыландырырга:

«а.1) Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан»;

түбәндәге эчтәлектәге «г» пунктчасы белән тулыландырырга:

«г) гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан»;

г) 10 нчы пунктта:

«б» пунктчасын «муниципаль хезмәткәрләргә» дигән сүзләрдән соң «керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат һәм» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

«в» пунктчасын «алар тарафыннан тапшырылган» дигән сүзләрдән соң «керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат һәм» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән «Посейдон» ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – «Посейдон» системасын) кулланып, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә (алга таба - дәүләт органнары һәм оешмаларына) аларның булган мәгълүматлары: гражданның яки муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында; граждан тарафыннан бирелгән мәгълүматларның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә дөреслеге һәм тулылыгы турында; муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында сорату (оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга яки аның

нәтиҗәләренә кагылышлы соратулардан, кредит оешмаларына, Россия Федерациясе Салым органнарына, күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен һәм аның белән килешүләрне гамәлгә ашыручы органнарга кагылышлы соратулардан тыш) җибәрергә;»

түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) Россия Федерациясенең ришвәтчелеккә каршы тору турындагы законнары нигезендә граждан яки муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны анализлауны (шул исәптән «Посейдон» системасын кулланып) гамәлгә ашырырга»;

д) 11 нче пунктта:

«в» пунктчасын «эше (хезмәте) сүзеннән соң «шәхесне раслый торган документның төре һәм реквизитлары» сүзләре белән тулыландырырга,»;

түбәндәге эчтәлектәге «е.1» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е.1) салым түләүченең идентификация номеры (Россия Федерациясе Салым органнарына сорату җибәрелгән очракта);»;

е) 12 нче пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләре белән алыштырырга, «7 статьяның икенче өлешендәге 7 нче пункты һәм 8 статьяның тугызынчы өлешен» сүзләрен «тиешле нигезләмәләр» сүзләре белән алыштырырга;

ж) 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләргә вәкаләтле яки муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүче вазыйфаи затка билгеләнгән тәртиптә доклад тапшырыла. Шул ук вакытта докладта түбәндәге җөмләләрнең берсе булырга тиеш:

а) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү турында;

б) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында;

в) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмау турында;

г) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

д) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә тикшерү материалларын тапшыру турында.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы А.Н.Фәйзуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯДЫГЕРЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ОГРН 1021607752836
Совет Ядыгерьского сельского поселения
ИНН 1623001639